СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**30.05.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 155**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләрне билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Зеленодольскшәһәре Советы **карар кылды**:

1. 1 нче кушымтада каралганча, җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләрне билгеләргә.
2. Зеленодольск шәһәре Советының 2023 елның 14 июнендәге «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләрне билгеләү турында» 119 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Советы рәисе М. П. Афанасьев**

Зеленодольск шәһәре Советының 2024 елның 30 маендагы 155 номерлы карарына 1 нче кушымта

Җирле салымнар суммалары өлешендәге бурычлар түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә исәпләнелә торган, түләү һәм (яисә) түләттерү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендәге бурыч түбәндәге нигезләр буенча түләтүгә ышанычсыз дип таныла:

1)варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яисә индивидуаль эшкуарларга исәпләнелә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар (белешмәләр) булып түбәндәгеләр тора:

1)әлеге Законның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә, физик затны салым исәбеннән алу хакындагы белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммалары хакында оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда –500 сумнан артмаган суммада бурыч булу хакында салым органы белешмәсе.